## БУ КЫЗЫК



♦ **Апрель. 2017.**

Татарстан матбугаты көне алдыннан “Татмедиа” нәшрият комплексына сәяхәт кылдык. Иң кызыгы — “Ялкын” журналы, “Сабантуй” газетасы журналистларын һөнәри бәйрәмнәре белән котладык. Сүз бирәбез: үскәч менә дигән журналист булырбыз әле!

♦ **Апрель. 2017.**

“Идел-Пресс” нәшрият-полиграфия комплексында без китап-дәреслекләрнең, газета-журналларның ничек басылуын күзәттек. Мәһабәт имән агачларыннан кеше укырлык газета чыгару өчен күпме көч сарыф ителәә икән! Гаҗәеп кызык һәм кирәкле һөнәр бу — газета чыгару!





♦ **Апрель. 2017.**

Без Татарстан Язучылар Берлегенә кунакка бардык. Язучылар Вакыйф абый Нуриев, Рәис абый Төхфәтуллиннар безне йөзьяшәр бина белән таныштырды. Биредә «Тукай» клубы да эшләп килә икән. Нинди тарихи бина бу!

**“КЫЗЛАР ИЛЕ” ГАЗЕТАСЫ РЕДАКЦИЯСЕ**
**Безнең адрес: 420034, Татарстан, Казан ш., Декабристлар ур., 89А.**
**Тел/факс: (843) 562-25-43**
**E-mail: kzlar_ile@mail.ru**

**Баш мөхәррир:** Рәмилә ГАЗИЗУЛЛИНА
**Шеф-мөхәррир:** Әхмәтҗанова Лилия Марсовна

**Редколлегия:** «Нур» балалар оешмасы
**Фотограф:** Юлия Кузнецова

***ЗЫЯЛЫ КЫЗ — ИЛ КҮРКЕ!***

# КЫЗЛАР ИЛЕ

**Ф.Г. Аитова исемендәге татар телендә белем бирүче 12 нче гимназия укучылары газетасы**
**2012 елның февраль аеннан бирле чыга**
6+
№2 (7) Апрель 2017 ел

## Бүгенге санда:

- ***Туфан абый сагындыра...*** *3-4 битләр.*
- ***“Кызлар иле” газетасының махсус кушымтасы.*** *6-7 битләр.*
- ***Фатиха Аитова истәлекләре.*** *5 бит.*
- ***Парламент дәресе.*** *8 бит.*
- ***Иcте Болгар җилләре...*** *10 бит.*
- ***Миңа илһам килде!*** *11 бит.*



**Акыллы сүз теш ярып чыгар**

***«Татар кешесе! Укы! Гыйлемле-белемле бул! Кушканны гына эшләүче түгел, үзең дә иҗади дәрәҗәдә эшләрлек зур белемгә ия бул...»***

***Туфан Миңнуллин.***

***Кадерле укучым! Синең алда – “Кызлар иле” газетасының яңа саны. Хөрмәтле остазыбыз, әйдәп баручыбыз Туфан ага Миңнуллинның бик тә гыйбрәтле әйтеме бар: “Кызлар теле — бәлеш төбе...” Шулай итеп, монда без сине иң татлы “бәлеш төбен” авыз итәргә чакырабыз. “Кызлар иле”нә рәхим ит, дустым!***

***Редакция.***

# Мәңге сүнмәс маяк Сез!



Татарстаныбызда күпме шагыйрь, язучы булса да, халык йөрәгенә яткан, үз халкы белән горурланган һәм шул ук вакытта гаиләсенә тугры булган, язган һәр сүзе чын йөрәктән бәреп чыккан шагыйрьләр, язучылар бик сирәк. Шундыйларның берсе — Туфан абый Миңнуллин... Мин үземне бик бәхетле дип саныйм. Чөнки мин нәкъ Туфан абый ярдәме белән төзелгән Фатиха Аитова исемендәге татар телендә белем бирүче 12 нче кызлар гимназиясендә белем алам.

Гимназиябездә Туфан абыйны барыбыз да хөрмәт итә. Без аны бик яратып, сагынып искә алабыз. Туфан абыйның хәләл җефете Нәҗибә ханым Ихсанова, кызы Әлфия ханым, оныклары — гимназиябезнең көтеп алынган хөрмәтле кунаклары. Гимназиябездә Туфан абый башлап җибәргән күркәм гадәтләрне — татар телен камил белгән, иң актив укучыларга ай саен кадерле Остазыбызның премиясен, 11 нче сыйныфны тәмамлаган уку алдынгысына көмеш беләзек тапшыруны аның гаиләсе дәвам иттерә.

Күптән түгел генә гимназиядә Туфан аганың якты истәлегенә багышланган “Хәтер залы” ачылды. Хәзер инде барыбыз да аның тормыш мизгелләре, шәхси әйберләре белән якыннан таныша алабыз. Бу гимназия өчен генә түгел, барлык татар дөньясы өчен дә сөенечле вакыйга!

...Монда ишектән атлап керүгә үк күренекле драматург яшәгән чорга, аның дөньясына чумасың. Стенада эленеп торган портретыннан ниндидер нур, җылылык, яктылык бөркелгән кебек. Иҗат өстәлендә Туфан абыйның күзлеге, каләме



һәм язу машинасы булса, ян-якта аның китаплары һәм фотосурәтләре урнашкан...

Киләчәктә дә Туфан абыйның исеменә тап төшермичә, ул теләгәнчә телебезнең дәвамчылары, лаеклы милләт аналары булсак иде. Юлыбызны яктыртучы мәңге сүнмәс маяк Сез, Туфан абый!

**Ландыш СИРАҖЕТДИНОВА,**
**11 нче сыйныф укучысы.**



## Көз

Менә алтын көз килде.
Яфраклар белән күмде.
Күп байлык һәм уңышлар
Ул безгә алып килде.
Матур-матур яфраклар
Очалар да, очалар.
Кубәләктәй бөтерелеп,
Иңнәремә төшәләр.

**Мәдинә ЛАТЫЙПОВА,**
**7 нче сыйныф укучысы.**

## Ко Дню пожилых

Бабушки, дедушки, вечно живите!
Счастье, здоровье себе сохраните!
Будьте в душе вы всегда молодыми,
Добрыми, милыми, всеми любимы!
Жизнь пусть подарит вам радостных дней!
Каждых поступков и всех ваших слов
Цену, чтоб знали, дарили любовь!

**Розалина ГАБДУЛЛИНА,**
**ученица 11 класса.**

## Дәү әнием

***Бу шигъри юлларны кадерле әбием Гөлнәфискә багышлыйм. Ул Биектау районы Юртыш авылында гомер кичерә.***

Әбием, мин сине яратам!
Син уңган-булган кеше.
Бар да синең кулдан үтә,
Бар синең төрле эшең.
Үзең чибәр, телең татлы,
Пешерәсең искиткеч!
Көтеп алабыз гел сине,
Сагынабыз син киткәч.

Татар телен син өйрәттең,
Яраттырдың җырларны.
Сездә авылда күп таптым
Мин үземә дусларны.

Уку башланды, мин инде
Каникулны көтәмен.
Сезгә кайтасы көннәрне
Санап арып бетәмен.

Синең мине яратуың
Күчә минем йөрәккә.
Сәламәт бул, озак яшә!
Син безгә бик кирәк лә.

**Яна СЕЛИВАНОВА,**
**9 нчы сыйныф укучысы.**

## Солдат хаты

Аяз күктә ак болытлар
йөзә.
Әйтерсең лә мамык
кораблар...
Чит илләрдән безгә –
туган якка
Ашыга-ашыга хатлар
ташыйлар.

Әй, “почтальон”!
Тукта бер минутка!
Ишет минем сәлам
хатымны.
Сөйләп бир син
дуслар, туганнарга
Телгә алып минем атымны.


Әйт син болыт
дуслар, туганнарга
Тиздән кайтыр,
көтегез, дип.
Сау-сәламәт,
зур медальләр асып,
Сезгә җиңү алып
кайтыр, дип.

Тукта кораб, кая
ашыгасың?
Тукта инде, сөйләп
бетерим...
Сөйгәнемә әйт син,
көтсен мине.
Әй, кояшым, бәгырь
кисәгем.

Эх, ак болыт!
Ничек итеп кенә
аңлатыйм соң йөрәк
ярамны?
Аңлатсам да,
тапшыралмассың син,
Тапшыралмассың сәлам
хатымны.

Кая барыйм,
кемгә генә сөйлим?
Кемнәр генә мине аңлый
ала?
Бәлки әле шушы
ак болыттай
Үзем кайтырмын туган
якларга.

**Ландыш СИРАҖЕТДИНОВА,**
**11 нче сыйныф укучысы.**



# Иске Болгар җилләре...

*Алма битләремне назлап*
*Иске Болгар җилләре.*
*Дәверләрне кичеп килдем,*
*Изге Болгар җирләре!..*

Болгар якларына барып кайту шушы шигырь юлларын язарга илһамландырды. Йөз тапкыр сөйләгәнче, бер күреп кайту яхшырак дип, белмичә генә әйтмиләр икән шул. Шәһри Болгар турында күпме генә укысам да, никадәр ишетсәм дә, мондагы гүзәллекне күз алдыма да китерә алмаганмын...

2016 елның 22 сентябрендә безнең 12 нче кызлар гимназиясеннән 8 нче, 9 нчы, 10 нчы сыйныф укучылары, укытучылары белән Изге Болгар якларына юл тотты. ...Автобусның ишекләре ачылып китү белән бөтенебез дә урамга ашыктык. Каршыбызда бөтен Татарстанга танылган - Ак мәчет. Яше нәни генә булса да, ул миңа бик легендар мәчет булып тоелды. Мәчет мәйданы уртасында - фонтан, ә ян-яктагы биек колонналар аны тагын да зурайтып, баетып тора. Әлбәттә, без монда үзебез генә түгел идек. Бу гүзәллекне күрергә тагын бик күп кешеләр җыелган. Бертуктаусыз фотога, видеога төшерәләр. Читтән карап торганда, чыннан да, бик кызыклы күренеш бу. Әмма, бөтенесе дә Изге Болгар тарихын белеп бетермидер шул. Безгә автобуста барганда китапханәчебез Равилә Зиннәт кызы кызыклы тарихи вакыйгалар турында сөйләп барды.

Болгар IX-X гасыр чикләрендә барлыкка килгән. Ул үзенең төзүчеләре белән дан тоткан. Осталар кулы белән салынган хәрабәләр бик күп булган. Кызганыч, хәзерге көндә аларның бик азы гына сакланып калган. Бу диварларны күргәч, куңелне ниндидер шом биләп ала. Шунда ук монда яшәгән халыкларны, булган вакыйгаларны кузаллый башлыйсың. Бер мизгелгә генә әби-бабаларыбыз тарихына чумасың...

Без инде бик түземсезләнеп, икенче тарихи бинаны күрү теләге белән янабыз. Хыялларыбыз акланды! Без XIII гасырның икенче яртысында төзелгән гаҗәеп зур Хан мәчете, икенче төрле итеп әйтсәк, Җәмигъ мәчетен күрдек. Әлбәттә, бу бинаның яртысын-нан күп өлеше юкка чыккан. Шулай да без аның сакланып калган диварларыннан күзебезне ала алмадык. Ул башта буе — 34, иңе 32 метрлы дүртпочмаклы таш бина рәвешендә булган. Күпмедер вакыт үткәч, мәчетнең һәр почмагын өстәмә дүрт манара белән ныгытканнар. Шулай итеп, мәчет гыйбадәт кылу урыны да, дошманнардан саклану урыны да булып хезмәт иткән. Чираттагы күз явын алырлык биналар — Кара Пулат белән Кече



Манара. Хикмәт шунда, XIV гасыр урталарында төзелгән булсалар да, алар бик яхшы сакланып калган.

Кузгалдык! Болгарда күптән түгел генә калкып чыккан “Икмәк” музеена юл тотабыз... Музей алды мәйданчыгы милли бизәкләр белән бизәлгән чын авыл инде менә! “Авыл” мәйданчыгына кергәч, иң беренче гаҗәеп зур һәм биек җил тегермәненә игътибар иттек. Уртада су тегермәне эшләп утыра, суда үрдәкләр йөзә, чирәмдә тавык-чеби йөгерә, ат-сыер сыйлана... Бер сүз белән әйткәндә — авыл романтикасы!

Хуш исле Болгар икмәге борыннарны кытыклый, андый икмәкне бүтән бер җирдә дә очратмассың! Эх, күпме сөйләсәм дә, сүз белән генә аңлатып бирә торган түгел ул могҗизалы Болгарны. Шулай мәңге балкы, Шәһри Болгарым!

**Ландыш СИРАЖЕТДИНОВА.**
**Казан - Болгар.**



# Туган көнең белән, Туфан ага!



12 сентябрьдә Туфан абый Миңнуллин фатирында күренекле драматургны искә алу кичәсе узды. Гадәти кичә түгел бу. Миңнуллиннар гаиләсенең әдәби-музыкаль “өй кичә-се” дип әйтсәк, дөресрәк булыр. Әлеге кичәләрне газиз әтисенең рухын шатландырып, Әлфия ханым Юнысова узган ел оештыра башлаган. Разил Вәлиев, Фәрит Бикчәнтәев, Альбина Шаһиморатова, Исмәгыйль Шәрәфи-ев һ.б. татар зыялылары Туфан аганы искә алган бирედә. Инде безнең гимназиягә дә чират җитте...

“Сентябрь – яңа уку елы башланган чак. Шуңа күрә без бу сезонны 12 нче кызлар гимназиясе белән очрашудан башлап җибәрергә уйладык. Сезнең гимназия – Әти күңелендә аерым бер урын биләп тора иде”, - дип башлады сүзен Әлфия ханым. Директорыбыз Илһамия ханым Темиркәева, Туфан аганың якташы, безнең гимназиядә укучы Алисә белән Энҗенең әтисе Эдуард Рәхмәтуллин да Туфан аганы тирән юксыну белән искә алдылар. Җырчы кызларыбыз Әдилә Мозафарова белән Энҗе Рәхмәтул-лина күңелләребезне җыр белән назлады... Кичәнең тагын бер күркәм гадәте – Әлфия ханым Туфан аганың “Утырып уйлар уйладым” китабыннан язучының “тешле” мәкаләләрен укыды. Монда без Санкт-Петербургтан килгән рәссам Рәшит Гыйләҗев белән дә таныштык. Ул Туфан ага әйтеп калдырган соңгы васыятьне үтәгән – щепкинчыларның портретларын иҗат иткән. Күренекле артистка, драматургның тормыш иптәше Нәҗибә ханым исә бу кичәләрнең узуына сөенеп туя алмый. Ул әледән-әле: “Бүген Туфанның туган көне”, - дип кабатлый иде... Туган көнең белән, Туфан ага! Сез гел безнең янда кебек.

**Рәмилә ГАЗИЗУЛЛИНА.**

## *Кадерле хатирәләр...*



Без әтием белән Туфан Миңнуллинны искә алу кичәсендә катнашу бәхетенә ирештек. Әтием исә Туфан абыйның үзе өчен аеруча кадерле кеше икәнен әйтеп узды. Туфан абый — безнең якташыбыз. Әтиемнең дәү әтисе аны Кама Тамагы районы Олы Салтык мәктәбендә математика фәненнән укыткан. Әтием белән әнием студент чакта Туфан абый идеясе буенча оештырылган Кама Тамагы студентлары очрашуында катнашканнар.

Кайчандыр Туфан абый утырган табын янына җыелып, хатирәләрне барладык, чәй эчтек, ахырда “Туган тел”не җырладык... Туфан абыйның рухы шат булсын!

**Энҗе РӘХМӘТУЛЛИНА,**
**7 нче сыйныф укучысы.**

***Килеп җитте! Хөрмәтле укытучыларыбызны Яз бәйрәме, Тукай айлыгы белән котлар чак җитте... Безнең редакция почтасына да кочак-кочак хатлар “ява” башлады. Кемнән, дисезме? Әле бу җәйдә генә укуларын тәмамлап, кулларына аттестат алган чыгарылыш укучыларыннан... Бәхетле студентлардан!***

## *Шомырт чәчәгедәй хуш исле балачак !*



Балачак дигән сүзне ишетүгә, мин чәчәк атып утыручы шомырт агачын күз алдыма китерәм. Чәчәкләре ап-ак, ә исе!.. Исе бөтен тирә-юньгә таралган. Балачак та шундый хуш исләрдән генә тора кебек. Бөтен нәрсә яңа, кызык...

Кечкенә чакта мин бик шук, тынгысыз, тиктормас бала булганмын. Күгәрмәгән, сыдырылмаган, бәрелмәгән җирем булмаган диярлек. Әнием чиста-пөхтә кызлары белән йөрүче әниләргә кызыгып карый торган булган, чөнки мин матур күлмәкләремне, тиз арада егылып, пычратып куйганмын. Мин боларны хәтерләмим, әнием сөйләгәннәрне буенча гына беләм. Ә Кыш бабайның миңа чыршы астында бүләк калдыруы минем мәңге исемдә булыр. Ничә яшьләр булгандыр (без ул вакытта Чаллыда яши идек), мин уйнап йөрим, әни кер үтүкли, әти кухняда чәй әзерли. Залда чыршы бизәлгән. Мин чыршы тирәли уйнап та арыдым, бүләк көтәм, ә бүләк юк. Әти безне чәй эчәргә чакырды, Кыш бабай мине онытты дип, күңелсезләнеп, әни артыннан мин дә чыктым. Чәй эчтек. Мин, иң беренче булып өстәл яныннан торып, залга кереп киттем. Керсәм... Чыршы астында - бүләк! Бүлмәгә миннән башка беркем дә кермәде. Әниләр кухняда, димәк, Кыш бабай мине онытмаган, ул мине ярата, ул мине белә! Мин бу мизгелне һич онытмыйм. Менә хәзер яздым да, яңадан шул вакытка кайтып килгәндәй булдым. Эх син, хуш исле балачак!

**Рәзилә ХУҖИНА,**
**1 нче курс студенты.**
**Рәсемдә: сыйныф җитәкчебез Алмаутова Рузилә Гарифулловна белән.**

## *Яз, Тукай ае белән, Укытучы!*

Рәхмәт сезгә, Укытучылар!
Күпме гыйлем җыйдык без!
Тормыш үрләренә менеп,
Максатларга җиттек без!
Күркәм бәйрәмегез котлы булсын!

**Сезне яратып, гимназиянең**
**чыгарылыш укучылары.**





***11 нче сыйныф укучыларының татар теленнән язган иншаларыннан фикерләр тезмәсе...***

# ӘГӘР МИН ДЕПУТАТ БУЛСАМ...



Депутат булырга бик авыр дип уйлыйм. Минемчә, депутат җаваплы, укымышлы һәм кыю кеше булырга тиеш. Әгәр мин депутат булсам, шәһәребездә күп нәрсәне үзгәртер идем. Казанда күп кеше үзенә ошаган эш таба алмый. Мин эш урыннарын булдырыр өчен бөтен көчемне куяр идем. Транспортка килсәк, мин пычрак автомобильләрне бөтенләй шәһәр эченә кертмәс идем. Чөнки алар һаваны пычраталар. Тагын мин барлык балаларга да шәһәр транспортында түләүсез йөрергә дигән закон чыгарыр идем...

**Ильвина ФӘЙРУШИНА.**

...Илебездәге бөтен законнарны үзгәртер идем. Мәктәптә укучы балалар өчен ашауны түләүсез ясар идем. Институтларда барлык студентлар да дәүләт хисабына гына укырлар иде. Мәктәпләрдә фәкать үз эшен ярата торган, балаларга яхшы белем бирә торган укытучыларны гына калдырыр идем...

**Карина ХӨСӘЕНОВА.**

Менә мин – депутат! Иң беренче эш итеп, күп балалы гаиләләргә акчалата ярдәм күрсәтер идем. Икенчедән, читтән күченеп кайткан яшь гаиләләрне йорт һәм эш белән тәэмин итүне, балалар өчен бөтен таләпләргә җавап биргән шартлар булдырыруны уйлар идем. Әйе, сабыйларга уен мәйданчыклары, кызыну һәм балык тоту урыннары төзү бик күп акча сорый. Әмма мин балалар өчен акча кызганырга җыенмыйм!

**Альбина ГАЛӘВЕТДИНОВА.**

Мин гел гимназиягә барганда урамда йортсыз этләрне, песиләрне күреп, аларны бик җәллим. Әгәр мин депутат булсам, аларга заманча хастаханә ачыр идем...

**Диёра РӘШИДОВА.**

Мин депутат булсам, әти-әниләрнең хезмәт хакларын арттырыр идем, һәм илебездә тынычлык булуын теләр идем.

**Рәзинә САФИНА.**

Халык өчен мөһим рольне табигать уйный. Табигать — безнең йортыбыз, аны саклауга юнәлдерелгән законнар кабул итәр идем.

**Азизә ИБРАҺИМОВА.**

# “Дәүләт Советына депутат булып килегез, кызлар!”



2017 елның 22-27 апрель көннәрендә республика мәгариф учреждениеләрендә парламент дәресләре узды.

22 апрельдә Татарстан Республикасы Дәүләт Советында Әлмәт шәһәренең 7 нче мәктәп укучылары ТР Дәүләт Советы рәисе Фәрит Хәйрулла улы Мөхәммәтшин һәм ТР Мәгариф һәм фән министры Энгель Нәвап улы Фәттахов белән очрашса, 24 апрельдә Фатиха Аитова исемендәге 12 нче гимназиянең 9-11 сыйныф укучылары депутат, шагыйрь Разил Исмәгыйль улы Вәлиев уздырган парламент дәресендә катнашты.

Әлеге дәреснең үзенчәлеге – Разил әфәнде дәресне тулысынча татар телендә алып барды. Шулай ук безнең кызлар өчен ТР Дәүләт Советы буенча оештырылган мавыктыргыч экскурсия дә татар телендә булды.

Ниһаять, без көтеп алган парламент дәресе гимназиябез гимны белән башланып китте... “Безнең очрашуыбыз бик мәгънәле башланды. Бүгенге дәреснең эчтәлеге – дәүләт символлары турында булачак”, - дип, укучыларны сәламләде Разил әфәнде.

Татарстанның дәүләт символлары – флаг, герб, гимнныңраслану тарихын тәфсилләп сөйләгәч, Разил әфәнде безнең укучыларны кызыксындырган сорауларга да җавап бирде. Укучыларны БДИ, чит илдә уку, милли мәгариф проблемалары, Универсиада мәшәкатьләре, шагыйрь-депутатның тыгыз эш графигы һәм иҗаты, татар теле һәм әдәбияты сәгатьләренең кимүе һ.б. бик күп мәсьәләләр борчый икән. Бер укучыбызның: “Разил абый, ә без Дәүләт Советына депутат булып килсәк, Сез безне көтәсезме?” - дигән соравына ул аптырап калмады: “Озак көттермәгез! Безгә хатын-кыз депутатлар бик кирәк. Сезгә өметебез зур, кызлар! Шуны истә тотыгыз: бездә ил белән ирләр идарә итә, ирләр белән хатын-кызлар идарә итә...” – дип, ярымшаяру белән җавап кайтарды.

Парламент дәресе аягүрә басып, яңа гына “табадан төшкән” Татарстан Республикасы гимнын җырлау белән тәмамланды. Бу әһәмиятле һәм эчтәлекле дәрестән һәркем үзенә тормыш сабагы, яшәү илһамы алып кайтты. Татарстан Дәүләт Советында мәктәп укучылары өчен шундый кызыклы парламент дәресләре ел саен булып торсын иде. Рәхмәт Сезгә, Разил абый!

**Рәмилә ГАЗИЗУЛЛИНА.**

**Рәсемдә: гимназия укытучылары һәм укучылары ТР Дәүләт Советында депутат Разил Вәлиев белән.**



***Әлеге сәхифәдә без сезне Казанда татар кызлары өчен беренче гимназия оештырган Фатиха ханым Аитова хатирәләре белән таныштырып барырбыз. Бу истәлекләрне укытучы Зәкия Рәсулева Фатиха Аитова гимназиясендә мөгаллимә булып эшләгән Гөлсем Сабитова сөйләгәннәрдән язып алган. Тарихи язманы без ТР Милли китапханәсендә саклана торган 1979 елгы “Сөембикә” журналыннан эзләп таптык.***

# Беренче карлыгачлар



Фатиха – элекке Оренбург өлкәсе Троицк шәһәренең Яушев дигән зур бай кызы. Үзе бик яшь, матур булуына карамастан, Казанның Сөләйман исемле өлкән яшьтәге бер сәүдәгәренә кияүгә чыгарга ризалаша. Ләкин Ләбибә апа кебек үк бер шарт белән: Фатиха апага атасы үлгәннән соң бик зур мирас – байлык тия, шул акчага татар кызлары өчен мәктәп салдырырга, аларны укытып, мәгърифәтле итәргә тели.

Озак та үтми, мәктәпнең план-проекты төзелә, раслана һәм, ниһаять, элеккн Екатерининская һәм Четырех Евангелистов (хәзерге Тукай, Татарстан) урамнары чатында махсус йорт салына.

Билгеле, бу мәктәптә дә мәҗбүри рәвештә беренче булып дин дәресләре укытыла. Ләкин инде шулар белән бергә уку, язу, хисап, география, тарих, рус теле һәм гаилә тормышы өчен кирәк булган аш-су, тегү-чигү эшләре дә өйрәтелә. Шулары белән ул абыстайлар укытуыннан аерыла да. 1916 елдан мәктәп “Татар кызлары өчен гимназия” итеп рәсмиләштерелә.

Фатиха апаның мөгаллимнәре **(рәсемдә)** барысы да яшьләр була. Билгеле инде, гаилә тормышы алып баруда тәҗрибәсезләр. Фатиха апа аларга:

- Кызлар, мине кияүгә бик яшьләй бирделәр. Миңа теләгәнчә укырга да, эшкә өйрәнергә дә мөмкинлек булмады. Тормыш итәргә дә тәҗрибәм җитәрлек түгел иде, бик читен булды. Сезгә дә, сез укыткан кызларга да шулай булмасын дип, мин мәктәпкә кул эше өйрәтү өчен кисү-тегү остасы чакырдым. Вера Сергеевна Моисеева ул. Әнә, мин бер сандык мануфактура китерттем. Һәркем шуннан үзенә кирәкне алып кисәргә, тегәргә, чигәргә өйрәнсен, - ди.

Вера Сергеевна кызларны чын күңелдән өйрәтә. Соңыннан мөгаллимнәр үз укучыларын да тегүчелек белән мавыктыралар. Укытучылар, укучылар теккән-чиккән әйберләрдән шәһәрдә зур күргәзмә оештырыла.

Беренче империалистик сугыш башлангач, бу мәктәп тә ситтә калмый: Фатиха апа материаллар алдырта һәм укытучылар, укучылар фронтка күлмәкләр, бияләйләр тегеп җибәрәләр.

Мәктәпнең яшь укытучылары осталар кул астында аш-су әзерләү курсын да үтәләр.

(Дәвамы бар.)

**Зәкия РӘСУЛЕВА.**

**“Сөембикә”, 1979 ел.**

# Яшәү рәхәт!

# Жить здорово!



## *“Сәләт” безгә очар канат бирде!*



Жәй, Биләр, палатка, учак һәм гитара... Бу сүзләрне нәрсә берләштерә? Әлбәттә, “Сәләт”. Быел, Биләр жирендә сәлкешләр 19 нчы тапкыр тантана итте. Монда икенче халыкара яшьләр форумы “Сәләт-Биләр — 2013” гөрләп узды. Биредә 5 мең кеше жыелды. 1996 елда әлеге тантана фестиваль дип аталса, 2012 елдан ул форум исемен алды. Раушан, Рухият, Бөгелмә, Биләр, Болгар, Азнакай, Биектау һ.б. аланнар да бирегә жыелды. Алар үзара төрле-төрле бәйгеләрдә катнаштылар.

Елдан-ел “Сәләт” камилләшә, үсә бара. Әйтик, бу форумның яңалыгы — “Сәләт-FM” радиосы барлыкка килде. Радио ди-джейлары Алисә Жамали белән Алмаз Гәрәев — бик оста дикторлар, һәр эфирлары бик кызыклы иде. Туры эфирда VIP-кунаклар да булды: Илназ Сафиуллин, Жәүдәт абый, Фәрит Бикчәнтәев, Әнвәр Хәйри, Фаяз Хужин, Айдар Габидуллин, Ләйсән Әсхәтова һ.б. Тагын бездә «Free Space» ясадылар. Анда сәлкешләр белән оештыручылар ял итте.

Форумның беренче көнендә үк бик зур концерт булды. Биредә әйдаманнар катнашты. “Сәләт-Азнакай” әйдаманнары биегәч, сәлкешләр аларны алкышларга күмде... «Сәләт»тәге уенлы дәресләрне, кызыклы мастер-классларны, остазларыбызны, сәлкешләрне юксынам. Эх, минем тагын шул мизгелләрне кайтарасым килә!

“Сәләт” форумының ачылу тантанасына Татарстан Республикасы президенты Рөстәм Нургали улы Минниханов та килде. “Сез — Республикабызның киләчәге! - диде ул. — Ел саен Биләр жире матурлана бара, “Сәләт” белән матурлана ул!”

Сәләт-Биләр, рәхмәт сиңа!

**Әдилә МОЗАФАРОВА,**
**11 нче сыйныф укучысы.**
**Рәсемдә: ТР президенты Рөстәм Миңнеханов - «Сәлкешләр илендә».**
**Казан - Биләр.**





# Отдых на острове Крит



***Мы так долго ждали этих каникул, что все разъехались в разные стороны нашей республики, а кто-то даже оказался в другой стране. А хотите узнать, как я провела лето?***

Я отдыхала в деревне, в Казани. Но больше всех мне понравился отдых на острове Крит (Греция). Спросите почему я поехала именно в эту страну? Мы с мамой долго выбирали, куда нам поехать. Но остров Крит нам понравился тем, что это удивительно красивый и древний остров.

И вот настал наш запланированный день вылета. Мы приехали в аэропорт, получили билеты и сели в самолет. Этот волнительный момент взлёта, ты пристегиваешь ремни безопасности и через несколько минут ты уже в небе!

...Через четыре часа мы уже были в городе Ираклион. Когда мы приехали в наш отель, нам дали уютный и красивый номер. С балкона был великолепный вид на море. Море было очень красивое!

Каждый миг мы старались проводить очень интересно и с пользой. Так как мы приехали только на семь дней. Так вот, моя мама интересовалась национальной кухней Греции. Оказывается, в Греции рестораны называются “тавернами”. Все они привлекали изысканным ароматом блюд, все столы были накрыты белоснежными скатертями. Мы выбрали одну таверну, которое находилось под кронами больших деревьев. Нам предложили меню с огромным выбором блюд. Мы попробовали блюдо под названием “Мусака”, греческий салат...

На третий день нашего отдыха мы решили посетить Океанариум. Мне безумно там понравилось. Столько разнообразных, удивительных рыб еще не видела! А самое впечатляющее - это были акулы! Также я видела осьминога, мурену, морского ежа и еще множество интересных морских животных.

Предпоследний день был самым интересным. Мы поехали на Критский вечер. Долго гадали, чтобы это значило? И вот нас - туристов повезли высоко в горы - в критскую деревню. Вот мы оказались на месте, нас встретили парни и девушки в национальных костюмах. Звучит живая национальная музыка! Всех гостей провели в жилье-музей греков. Мы познакомились с бытом и обычаями греческого народа. Но дальше было самое интересное - нас посадили за большой стол покрытой белой скатертью. И тут в неожиданный момент начались веселые народные танцы! И потом всех нас тоже позвали танцевать. Это было незабываемо весело!

Но все хорошее, когда-нибудь кончается... Наступил наш последний день отдыха. Настроение было прекрасное! Хоть мы и мало были в чужой стране, но уже успели соскучиться по своему родному Татарстану.

**Ильвина ФАЙРУШИНА,**
**ученица 11 класса.**
**Казань - Греция.**